| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 31 гыйнвары №1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль Законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнвары 57 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 7793,48 сум күләмендә, 1, 2 кушымталары нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гарантияле күмү хезмәтләре исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк поселогы, Заречная ур., 25, Үзәк ур., 12А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Валиәхмәтов

Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1нче кушымта

Татарстан республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе 2023 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2945,95 |
| 3. Мәрхүмнең гаүдәсен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1480,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 3366,78 |
| Барлыгы | **7793,48** |

Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Җирләү һәм күмү эше турында» ФЗ-8 нең 12 статьясы нигезендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлегенең бәясе 2023 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Гәүдәне төрү | 972,17 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1973,78 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1480,75 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 3366,78 |
| Барлыгы | **7793,48** |